БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ
ВСЕМИРНЫЙ КОНГРЕСС ТАТАР
WORLD CONGRESS OF THE TATARS

420060, Казань-60, Всемирный конгресс татар,
тел.: (843) 236 59 16, факс: (843) 264 63 37
www.tatar-congress.org

420060, Казан шәһәре,
Бөтендөнья татар конгрессы
тел.: (843) 236 59 16, факс: (843) 264 63 37
E-mail: tatar-congress@mail.ru

Исх. № 19-045 от «17» 01, 2019

на №

**Татарстан Республикасының
чит илләрдәге вәкилләренә**

**Чит илләрдәге татар
иҗтимагый берләшмәләре һәм
милли-мәдәни үзәкләре
җитәкчеләренә**

***2019 елда максатчан нигездә Татарстан Республикасы
югары уку йортларына укырга керү турында***

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, ТР мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсе нигезендә Россия гражданнары, БДБ илләрендә һәм ерак чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезне Татарстан территориясендә урнашкан Россия Федерациясенең югары уку йортларына максатчан нигездә укырга керүдә ярдәм итү эшен дәвам итә.

Агымдагы елның **1 маена кадәр** Бөтендөнья татар конгрессы сайтында абитуриентларның анкеталарын тутырулары сорала. Шулай ук абитуриентларның паспорт һәм уку турындагы документларының күчермәләрен rustemsaid@bk.ru электрон адресы буенча Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетына җибәрүегезне сорыйбыз. Документларның оригиналлары турыдан туры уку йортларына абитуриентлар тарафыннан тапшырыла.

Быел БТК Башкарма комитеты тарафыннан Татарстанда урнашкан югары уку йортларына медицина, икътисад, юридик белгечлек буенча гаризалар кабул ителми.

Абитуриентларга карата куелган таләпләр турында тулырак мәгълүмат уку йортларының рәсми сайтларында урнаштырылган.

**Ихтирам белән,
Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары,
Бөтендөнья татар конгрессының
Милли Шура рәисе** **В.Г.Шәйхразиев**